**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыЯңа Бүләк авыл җирлеге составына керүче Иске Теләнче авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАР**

05 ноябрь 2024 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Тукай муниципаль районы "Яңа Бүләк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлегенең Советы 30.11.2019 ел, № 43/1 «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында" нигезләмәне раслау хакында» карары белән 2024 елның 05 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2025 елда яшәү урыны буенча Яңа Бүләк авыл җирлеге Иске Теләнче авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз ) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, РФ Хәрби Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взнослар түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- Һәйкәлләр (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм янәшә территорияне төзекләндерү( Иске Теләнче авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга һәйкәл кую);

«ӘЙЕ» «ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 61 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 37 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 37 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Иске Теләнче авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.

2. «2025 елда яшәү урыны буенча Яңа Бүләк авыл җирлеге Иске Теләнче авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз ) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, РФ Хәрби Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә

әгъзаларын үзара салым буенча взнослар түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- Һәйкәлләр (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм янәшә территорияне төзекләндерү( Иске Теләнче авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга һәйкәл кую);

дип танырга.

3. Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Иске Теләнче авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4 . Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Иске Теләнче авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районыны рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Бүләк авыл җирлеге Башлыгы М.С. Сагетдинов